ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.06.2025 Балык Бистәсе штп №156пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында сугыш вакытында эвакуация чараларын оештыру турында" 26.05.2025 ел, №124пи карарына үзгәрешләр кертү турында

Норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатларында, «Гражданнар оборонасы турында» 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы Федераль закон, «Халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне имин районнарга эвакуацияләү тәртибе турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 30 ноябрендәге 2056 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә эвакуацияләнгән халыкны кабул итүне, урнаштыруны һәм беренче чиратта тормышны тәэмин итүне планлаштыру идарәсе органнары эшен оештыру максатларында КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында сугыш вакытында эвакуация чараларын оештыру турында" 26.05.2025 ел, №124пи карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының кабул итү эвакуация пунктлары исемлеген түбәндәге эчтәлектәге 27 пункт белән тулыландырырга:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 27. | Олы Кульга авыл җирлеге | Олы Кульга авылы мәдәният йорты | 422660, Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Олы Кульга авылы, Мәктәп урамы, 9 йорт | Олы Кульга Мәдәният йорты мөдире |

1.2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә оештырылган матди һәм мәдәни кыйммәтләрне кабул итү, урнаштыру һәм саклау пунктлары исемлеген яңа редакциядә бәян итәргә:

| № п/п | Җирлек исеме | Матди һәм мәдәни кыйммәтләрне кабул итү, урнаштыру һәм саклау пунктын (алга таба ПМКЦ) формалаштыручы, урнашу урыны, адресы | ПМКЦ начальнигы, төп эш урыны буенча вазифасы |
|---|---|---|---|
| 1. | ТР Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге | Олы Елга авылы Мәдәният йорты. 422640, Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Олы Елга авылы, Мәктәп урамы, 24А йорт | Миннегалиев Вакыйф Нургали улы, Олы Елга авылы Мәдәният йорты мөдире |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.К. Вафинага йөкләргә.

Җитәкче Д. А. Сатдинов

Республика Татарстан Исполнительный комитет Рыбно-Слободского муниципального района Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты
Р.07-3578/02
ИНН 1634005040